Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Урман-Кәләй авыл Советы

КАРАРЫ

12 декабрь 2024 ел № 101

Әлмәт муниципаль районы Урман-Кәләй авыл Советының 2007 елның 24 январендәге 35 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман-Кәләй авыл җирлегенең муниципальара хезмәттәшлектә катнашу тәртибе турында» карарының үз көчен югалтуын тану турында

Муниципаль хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерүгә бәйле рәвештә, хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча

Урман-Кәләй авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Урман-Кәләй авыл Советының 2007 елның 24 январендәге 35 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман-Кәләй авыл җирлегенең муниципальара хезмәттәшлектә катнашу тәртибе турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Урман-Кәләй авылы Кәләй тимер юл станциясе бистәсе, Железнодорожная урамы, 38б йорты; Колшәрип тимер юл станциясе бистәсе территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталына» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылганнан соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Урман-Кәләй авыл җирлеге башлыгы Фәләхиев Л.Н.